ГЛАВА ГОРОДА ЗАИНСКА
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЗӘЙ ШӘҺӘРЕ БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24.08.2026 г. Заинск № 09

**Кадастр номеры 16:48:060203:89 булган җир кишәрлегенә карата җир кишәрлегеннән файдаланунын шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында карар проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү хакында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 20 марттагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Зәй шәһәре Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2026 елның 21 августындагы 01-09-20182 номерлы хаты нигезендә

**карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы, Зәй шәһәре, Баныкин урамы, з/у 3 йорт адресы буенча урнашкан «сәүдә объектлары (сәүдә үзәкләре, сәүдә-күңел ачу үзәкләре (комплекслары)» 16:48:060203:89 кадастр номерлы, 4412 кв. м мәйданлы җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турындагы карар проекты буенча Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының «Зәй шәһәре» муниципаль берәмлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең күпфункцияле иҗтимагый-эшлекле зонасында (О-1) гавами тыңлаулар билгеләргә.
2. Гавами тыңлауларны оештыручы - коллегиаль киңәшмә орган составын расларга:
3. 1) Максимов С.В. – Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Башлыгы урынбасары;

2) Шакиров И.Н. – Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча);

3) Әгъләмов Р.В. – «Җир төзелеше бюросы» ҖЧҖ директоры (килешү буенча);

4) Оборина г. Ф. – Зәй муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасы рәисе вазифаларын башкаручы (килешү буенча);

5) Кудряшов В. В. – Зәй муниципаль районы Советының юридик бүлеге башлыгы (килешү буенча);

6) Усик О.В. – Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге баш белгече.

3. Гавами тыңлауларны оештыручыга - Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Башкарма комитетына җирле үзидарә, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында законнарына ярашлы рәвештә гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрүне тәэмин итәргә.

4. Гавами тыңлаулар үткәрү 2026 елның 24 сентябреннән да соңга калмыйча тәгәлләнергә тиеш дип билгеләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

**Зәй шәһәре башлыгы** **Р.Г. Кәримов**